ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**14.10.2017ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2609**

«2017 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре территориясендә уңайлы шәһәр мохите булдыру» муниципаль программасы турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы (29.07.2017 ред.), 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» (03.07.2016 ред.), 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» (03.07.2016 ред.) Федераль законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2017 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территориясендә уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасын (1 нче, 2 нче кушымта) расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәреннең хокукый мәгълүматның рәсми порталында ( http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
2017 елның 14 октябрендәге
2609 номерлы карарына
кушымта

# «2017 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территориясендә уңайлы шәһәр мохите булдыру» муниципаль программа

## Программаның паспорты

<table>
<tr><td>Программаның атамасы</td><td>«2017 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территориясендә уңайлы шәһәр мохите булдыру» муниципаль программа</td></tr>
<tr><td>Программаның дәүләт заказчысы</td><td>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүче</td><td>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты:</td><td>Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>-Җәмәгать киңлекләре территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру;<br>-Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга оешмаларның һәм гражданнарның җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2017 ел.<br>Программаны гамәлгә ашыру этапларга бүленми.</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп программаны финанслау күләме</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 166 000,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="2">Шул исәптән акчалар</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>166000</td><td>123000</td><td>43000</td></tr>
<tr><td>Барлыг</td><td>166000</td><td>123000</td><td>43000</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2017 ел нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>- җәмәгать киңлекләренең төзекләндерелгән территорияләре санын;<br>- җәмәгать киңлекләренең төзекләндерелгән территорияләренең гомуми мәйданын. |
| | - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәренең экологик торышын һәм тышкы күренешен яхшырту;<br>-Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре халкының уңайлы мохитен һәм тормыш эшчәнлеген булдыру.<br>Бу, үз чиратында, республика халкының икътисадый үсеше һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү факторы буларак, торак пунктларның киләчәк үсешенә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә нык этәргеч бирәчәк. |

1. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, шул исәптән Программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемалар

Яшәү мохите - яшәү өчен киңлек тә, ресурсларның бик мөһим чыганагы да ул, ул кешеләрнең рухи дөньясына, аларның сәламәтлегенә һәм тормыш эшчәнлегенә зур йогынты ясый.

Бүген кеше капиталы өчен бизнес кына түгел, шәһәрләр һәм илләр дә көндәшлек итә. Нәкъ менә шуңа күрә, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 124 номерлы карары белән расланган, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үстерү стратегиясе өстенлекле юнәлешләрнең берсе буларак, тормышның югары сыйфатлы, уңайлы яшәү мохите һәм кешенең тормыш эшчәнлеге өчен шартлар тудыру билгеләнде.

Яшәү уңайлылыгы муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсе урамнарны, паркларны һәм скверларны яктырту, кече архитектура формаларын урнаштыру, балалар өчен спорт-уен мәйданчыкларын, өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыкларын оештыру, шәхси транспорт урнаштыру мәйданчыкларын тәртипкә китерү, йорт хайваннарын йөртү мәйданчыкларын оештыру белән билгеләнә:

Төзекләндерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары - җәмәгать катнашуы, шәһәр мохитенә системалы караш, барысы да ишегалларыннан башлана, заманча җәмәгать зоналары, шәхси җаваплылык «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» өстенлекле проектта формалаштырылган.

Зеленодольск шәһәрендә паркларның, скверларның гомуми мәйданы 2017 ел башына 384 839,1 кв.м тәшкил итте.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары, көтелгән соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программа «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» өстенлекле проекты белән федераль дәрәҗәдә билгеләнгән төзекләндерү өлкәсендә дәүләт сәясәте өстенлекләрен һәм максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Программаның максаты Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру.

Күрсәтелгән максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

җәмәгать киңлекләре территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру;

Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга оешмаларның һәм гражданнарның җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру.

Программа чараларын гамәлгә ашыру 2017 ел нәтиҗәләре буенча җәмәгать киңлекләренең төзекләндерелгән территорияләре санын, җәмәгать киңлекләренең төзекләндерелгән территорияләренең гомуми мәйданын 30,5 мең кв.метрга арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2017 ел.

Программаны гамәлгә ашыру Зеленодольск шәһәрендә гомуми файдаланудагы иң күп йөри торган муниципаль территорияләрне төзекләндерү буенча чаралар комплексын үтәүне күздә тота.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу

Программаны финанслауның гомуми күләме 166 000,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 123 000,0 мең сум.

| Ел | Барлыгы акчалар | Шул исәптән акчалар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | шул исәптән | | федераль бюджет | шул исәптән | |
| | | | ишегалды территорияләрен төзекләндерүгә | җәмәгать территорияләрен төзекләндерүгә | | ишегалды территорияләрен төзекләндерүгә | җәмәгать территорияләрен төзекләндерүгә |
| 2017 | 166000 | 123000 | 50000 | 73000 | 43000 | | 43000 |
| Барлыгы | 166000 | 123000 | 50000 | 73000 | 43000 | | 43000 |

## 4. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру механизмы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрүдә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәренең җәмәгать территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны үтәү юлы белән дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне күздә тота.

Күрсәтелгән максатларга федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет акчаларының (алга таба – бюджет акчалары) төп бүлүчесе-Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.

Дәүләт заказчысы функцияләрен үтәүче һәм сатып алуларны, аукционнарны оештыруны һәм үткәрүне, дәүләт контрактларын төзүне гамәлгә ашыручы, заказчы-төзүче, генераль подрядчы һәм техник функцияләрен башкаручы «Татарстан Республикасының төп инвестицион-төзелеш идарәсе » дәүләт казна учреждениеесе Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәренең җәмәгать территорияләрен төзекләндерү буенча бюджет акчаларын алучы һәм чараларны башкаручы заказчы, проект документациясенә экспертиза үткәрүне тәэмин итә, төзелеш контроле үткәрә.

2017 елда төзекләндерелергә тиешле җәмәгать территорияләрен Программа проектына кертү турындагы тәкъдимнәрне тапшыру, карау һәм бәяләү тәртибе һәм сроклары; программа проектын җәмәгатьчелек белән фикер алышу тәртибе Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Программаны гамәлгә ашыруның оештыру механизмнары түбәндәге чараларны үтәүгә юнәлдерелгән:

- Программага кертелгән җәмәгать территориясен төзекләндерү дизайн-проектын кызыксынучылар белән фикер алышуны исәпкә алып раслау буенча;
- 2018-2022 елларга заманча шәһәр мохите булдыруның Татарстан Республикасы муниципаль программасын раслау буенча».

Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул Программаның максатчан күрсәткечләрен һәм чараларына чыгымнарны төгәлләштерә.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына квартал саен хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр тиешле бюджетлардан чараларны башкаручыларга тиешле бюджетлардан нәтиҗәсе арта барган һәм тулаем алганда хисап елында бүлеп бирелә торган акчаларның үтәлеше һәм аларны үзләштерү турында мәгълүмат тапшыра.

## 5. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа чаралары Зеленодольск шәһәренең тышкы күренешен яхшыртуга, Татарстан Республикасы халкының яшәү өчен уңайлы мохитен һәм тормыш эшчәнлеген булдыруга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын гамәлгә ашыру тискәре социаль-икътисадый нәтиҗәләргә китермәячәк.